Каралды:

Әтнә районы "Мәгариф бүлеге"
җитәкчесе
Гарипов Л.Т.

Раслыйм:

"Мәктәптән тыш эшләр үзәге"
өстәмә белем бирү учреждениесе
директоры Мәгъсумова Э.Р.

# «Шигъри дулкыннар» шигырь укучылар бәйгесе нигезләмәсе

(Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышлана)

**Максат:** Укучыларда туган телне тирәнтен өйрәнүгә кызыксыну уяту, татар милләте белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Бурычлар:** Укучыларда татар телендә камил, дөрес итеп сөйләшү, аралашу күнекмәләрен үстерү,аларны татар шагыйрьләренең иҗатлары белән таныштыру.

**Конкурсны үткәрүчеләр:**
"Мәктәптән тыш эшләр үзәге" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе( алга таба "Мәктәптән тыш эшләр үзәге") Әтнә районы "Мәгариф бүлеге" белән берлектә

**Үткәрү көне: 25 нче февраль , 2021 нче ел вакыты: 12.00 сәгатьтә**

**Үткәрү урыны:** Олы Әтнә урта мәктәбенең башлангыч сыйныфлар бинасы,актлар залы

**Конкурста катнашучылар:** Олы Әтнә урта мәктәбенең башлангыч сыйныф һәм "Мәктәптән тыш эшләр үзәге" укучылары.

Конкурста катнашучы башлангыч сыйныф укучыларының чыгышлары 2 төркемгә бүлеп бәяләнә:

1 нче төркем : 7-9 яшьлек укучылар
2 нче төркем : 10-11 яшьлек укучылар

Һәр сыйныфтан һәм берләшмәдән 2 укучы катнаша ала.

**Конкурсның төп тематикасы** – туган тел, халыклар бердәмлеге турында татар, рус һәм башка милләт телләрендәге шигырьләр. Шулай ук туган ил, туган як, туган як табигате турындагы шигырьләр,балалар язучылары шигырьләрен файдалану хуплана.

**Бәяләү критерийлары:**
1. укучының дөрес дикция белән сөйли белүе;
2. интонация аша шигырьнең төп фикерен ача алуы;
3. шигырь укучының яшь үзенчәлекләренә туры китереп сайлануы;
4. укучының сәхнәдә үз-үзен тотышы, сәхнә культурасы; .
5. чыгышның тәгъдим ителгән тематикага туры килүе.

**Катнашучыларның чыгышына карата аерым таләпләр:**
- катнашучының чыгышы презентация , музыкаль бизәлеш белән баруы хуплана ;
- чыгыш шигъри әсәрдән алынган өзек булырга мөмкин.

**Конкурсны үткәрү һәм аңа йомгак ясау тәртибе:**
- Конкурста катнашучыларның чыгыш ясау тәртибе төркемнәрдә үткәрелгән җирәбә нигезендә алып барыла.
- Конкурста катнашучылар җюри алдында чыгыш ясый.
- Җюри әгъзалары карап үтелгән чыгышлар буенча нәтиҗә ясап, 2 төркемдә 1-2-3 урыннар билгели.
-Җиңүче укучылар конкурсның грамоталары белән бүләкләнә.

- Жюри конкурс нәтиҗәләре буенча шулай ук укучыларны аерым номинацияләрдә билгеләп үтәргә мөмкин.

-Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат " Мәктәптән тыш эшләр үзәге"нең рәсми сайтында урнаштырыла.

**Жюри составы:**

Фахретдинова Раиля Фоат кызы – "Мәктәптән тыш эшләр үзәге" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе методисты;

Нигматова Ләйсән Илфат кызы – "Мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе методисты;

Садриева Рита Ришат кызы - "Мәктәптән тыш эшләр үзәге" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе педагогы.